**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Якты Күл авыл җирлегенең Утяшкин торак пунктында**
**2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**22.11.2025 ел.** **№ 1**

«Хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең Утяшкин торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең Утяшкин торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2026 елда үзара салымны 600 сумм күләмендә билгеләргә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:
- торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ Беларуска асылма җиһазлар сатып алу);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү гидранты урнаштыру, Янгын җиңле колонка сатып алу).

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә (Якты Күл авыл җирлеге Уставының 69 ст. 5п.) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлеге башлыгы З.З. Мөхтәров